БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 10 2025 ел № 249

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча Пыжмара авыл җирлеге халкы катнашында гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгы И.Н.Сәгъдиев;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе И. М. Фәтхетдинов;

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты юридик бүлеге башлыгы Р.С.Фатыйхов;

- ГБУ "ФПД РТ" вәкиле.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар уздыру вакытын гавами тыңлаулар нәтиҗәсе белән кызыксынучы затларга аларны уздыру турында хәбәр итү вакытыннан башлап бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, дип билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы бер айдан артык була алмый.

5. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр әзерләргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль район
Башлыгы Р. Р. Нотфуллин